| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

***Постановление*** ***Карар***

**17.03.2023** **Чистай шәһәре** **№ 147**

Татарстан Республикасы
«Чистай муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге бюджеты
кытлыгын финанслау чыганакларының
баш администраторлары
исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясындагы 4 пунктының өченче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары, Россия Финанс министрлыгының “2023 елга (2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына) Россия Федерациясе бюджет классификациясенең кодларын (кодлар исемлеген) раслау турында»гы 2022 елның 17 маендагы 75н номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген Кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карар 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджеттан башлап Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләргә карата кулланыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (https://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенә йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 17 мартындагы
147 номерлы карарына
Кушымта

Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

| Бюджет дефицитын финанслауның чыганагы төре, төркемчәсе һәм кодының атамасы | Бюджет дефицитын финанслауның чыганагы төре, төркемчә, төркем кодының атамасы | Бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторы коды | Бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторының атамасы |
|---|---|---|---|
| 01 05 02 01 05 0000 510 | Муниципаль районнар бюджетларының башка калдык акчаларын арттыру | 802 | Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы |
| 01 05 02 01 05 0000 610 | Муниципаль районнар бюджетларының башка калдык акчаларын киметү | 802 | Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы |